ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 гыйнвар 2017 ел № 394

Башкарма комитетның «Торак урыннарга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 2 октябрендәге 5950 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Торак урыннарга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 2 октябрендәге 5950 номерлы карарына кушымтаның 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | 1) ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>- Бердәм дәүләт күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән килешүләр реестрыннан аерым затның булган (булучы) күчемсез милек объектларына аның хокуклары турында өземтә (ф);<br>- Бердәм дәүләт күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән килешүләр реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар) (Ф);<br>- Бердәм дәүләт күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән килешүләр реестрыннан күчемсез милек объектына хокукларны күчерү турында өземтә (Ф);<br>- үлүне дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар;<br>- РФ гражданының яшәү урыны буенча теркәлүе турында мәгълуматлар; | |

| | | |
|---|---|---|
| | - гаилә составы турында белешмә;<br>- торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турында карар (граждан яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урынында яшәгән очракта);<br>2) опека һәм попечительлек органнарыннан опекун билгеләү турында белешмә – хокукка сәләтсез граждан исеменнән эш итүче опекунны исәпкә кую турында гариза имзаланган очракта | |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин